**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы**

№14 КАРАР 14 октябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы " Ташкичү"
авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 44 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 86, 87, 88 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карары белән кабул ителгән «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**«Гражданнар җыены» 14 статьясындагы 14 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган Гражданнар җыены, анда торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыграгы катнашканда тулы хокуклы була. Торак пунктта, әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә катнашу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә, карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар киләсе этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары әгәр җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала".

2. Әлеге карарны закончалыкта билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләти теркәүдән соң әлеге карарны Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Ташкичү авыл җирлеге Башлыгы Р. Р. Вәлиев